СОВЕТ
СТАРОЧУРИЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Новая, д. 52, с. Старое Чурилино,
Арский муниципальный район, 422014

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ЧҮРИЛЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Яңа урам, 52 йорт, Иске Чүриле авылы,
Арча муниципаль районы, 422014

Тел. (84366)57-3-48,3-06-09 факс (84366)57-3-48, 3-06-09 E-mail: Shur.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге Советы карары**

**«28» октябрь 2024 ел** **№ 101**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлегенең Иске Чүриле авылында яңа урамнарга исем бирү турында**

«Татарстан Республикасының административ-территориаль төзелеше турында» 2005 елның 7 декабрендәге 116-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Адреслар бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару кагыйдәләрен раслау хакында» 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы карары, «Иске Чүриле авыл җирлегенең топонимика буенча комиссиясе турында» Иске Чүриле авыл җирлеге Советының 2010 елның 5 маендагы 32.1 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлегенең Иске Чүриле авылындагы яңа урамнарга түбәндәге исемне бирергә:

- Солнечная урамы
- Мирная урамы
- Каенлык урамы
- Радужная урамы

2. Дәүләт адрес реестрына түбәндәге адресларны кертергә: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, Иске Чүриле авыл җирлеге, Иске Чүриле авылы, Солнечная урамы; Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, Иске Чүриле авыл җирлеге, Иске Чүриле авылы, Мирная урамы; Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, Иске Чүриле авыл җирлеге, Иске Чүриле авылы, Каенлык урамы; Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, Иске Чүриле авыл җирлеге, Иске Чүриле авылы, Радужная урамы.

3. Иске Чүриле авыл җирлеге башкарма комитетына бер ай эчендә йөкләргә:

- "Иске Чүриле авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге урамнары исемнәре реестрына яңа төзелгән урам исеменәрен кертергә;

- яңа урамнарда адрес атрибутикасын урнаштыруны тәэмин итәргә;

- әлеге карарны гамәлгә ашыру буенча башка чараларны тормышка ашырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru), Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http:arsk.tatarstan.ru).

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Иске Чүриле авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Рамазанов